# ХАЛЫК ИҖАТЫНЫҢ ПОЭТИК ЖАНРЛАРЫНДА *“МӘХӘББӘТ”* КОНЦЕПТЫНЫҢ ЯШӘЕШЕ

**(мәкаль-әйтемнәр мисалында)**

Халыкның күп гасырлар дәвамындагы күзәтү һәм уйланулары нәтиҗәсе, аның хыял-өметләре, сүз мәгънәләрендә, тотрыклы сүзтезмәләрдә, табышмакларда саклану белән беррәттән, мәкальләрдә дә гәүдәләнеш таба. Әнә шул рәвешле, халык үзенең сәнгатен, шигъриятен һәм тормыш фәлсәфәсен тудыра. Мәкальгә бирелгән барлык әдәби билгеләмәләрне әйтеп чыгу бик кыен. Аны халык акылы, гамәли фәлсәфә, телдәге сабак, тормыш кагыйдәләре тупламасы, халыкның тарихи хәтере дип атыйлар.

Күпчелек кешеләрнең яшәү рәвеше һәм фикерләве белән тәңгәл килгән гыйбарәләр мәкаль-әйтемнәргә әверелеп, күп гасырлар буе сакланып кала алган.

Хәзерге лингвистика гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләре белән бәйләнешләрен арттыра, шул рәвешле аның тикшеренү өлкәсе киңәя һәм тел белеменең традицион өйрәнү объектларына яңа күзлектән карау мөмкинлеге туа. Мәкаль-әйтемнәр инде күптәннән өйрәнү-тикшерү объекты булуга карамастан, соңгы вакытларда паремиологик берәмлекләрне хәзерге теоретик юнәлешләрдән чыгып өйрәнү һәм классификацияләүгә яңача караш тудыру ихтыяҗы туды. [Җамалетдинов, 2006: 120].

Телнең халык иҗаты фонды лингвомәдәният һәм концептлар теориясе өчен, һичшиксез, әһәмиятле, чөнки әлеге фонд массакүләм милли акылның аеруча мөһим стереотипларын үзгәртеп торырга мөмкинлек бирә.

Без исә, үз чиратыбызда, халык иҗаты әсәрләре булган паремияләр һәм халык җырлары нигезендә, *“Мәхәббәт”* концептының халык авыз иҗаты әсәрләрендә яшәешен карадык.

Паремиологиядә исә *“Мәхәббәт”* концептына кыйммәти характеристика хас, ә мондый төр үзенчәлек бары тик лингвомәдәнияттә генә карала. Татар милли аңы өчен *“Мәхәббәт”* – кызыклы концептларның

берсе. Бу концептны белдерә торган *мәхәббәт* лексик берәмлеге – күпмәгънәле төшенчә, һәм бу үзенчәлек шулай ук *“Мәхәббәт”* концептына да хас. Татар паремиологиясендә әлеге концепт туган ил, туган җир төшенчәсе белән бәйләнә, һәм ул Ватан төшенчәсе белән тәңгәлләштерелә. Татар халкы аңында Туган җир, Ватан нииндидер бер якын, кадерле кеше, сөйгән яр булып күзаллана һәм мәкальләрдә дә шул рәвешле чагылыш таба: *Ватанны сөю – үзеңне сөю; Ватаннан аерылу сөйгәннән аерылудан яманрак.* Моннан тыш, туган якка, туган илгә булган *мәхәббәт* салкын кабер белән капма-каршы куела: *Туган илгә булган мәхәббәт салкын кабердә дә суынмас*.

Лингвомәдәни анализ барышында, мәдәни үзенчәлекләр һәм башка экстралингвистик факторларга бәйле булган телнең чагыштырыла торган берәмлекләренең эчтәлеге төп рольне башкара. Мәсәлән, *Ана мәхәббәте балада, бала мәхәббәте далада*. Бу мәкальнең универсаль, гомумкешелек компонентының мәгънәсенә игътибар итәргә кирәк. Балалар мәхәббәте дала белән чагыштырыла, ягъни аның мәхәббәте чиксез, ләкин кемне яратканын үзе дә белми. *Дала* лексемасы белән бәйле тарихи-мәдәни җирлек белемнәре булмаганда, әлеге мәкаль гыйбарәсен ишеткән башка мәдәният вәкилләрендә мәдәни яктан әһәмиятле, кыйммәтле мәгълүмат юкка чыга. Моннан тыш, татар халкында *мәхәббәт* – ике капма-каршы җенес вәкиле (егет белән кыз, ир белән хатын) арасында бер-берсенә карата туарга мөмкин булган бөек хис, һәм әлеге җылылык аларны гомер буена озатып барырга тиеш, ә *гыйшыклык* исә кешене кыска бер вакыт аралыгында биләп алырга мөмкин булган көчле хис дип карала: *Гыйшык уты кабына да сүнә, мәхәббәт гомер буе җылыта*. Мәхәббәтне бары тик мәхәббәт кенә яшәтә алырга сәләтле: *Мәхәббәт мәхәббәт белән яши.*

Татар хатын-кызларына хас булган сабырлык, тугрылык *мәхәббәт* өлкәсендә дә чагылыш таба: *Хатыннар мәхәббәтне күңелләрендә кырык ел саклarлар, сөймәгәнлекләрен бер сәгатьтә ачып салырлар.*

Ләкин икенче бер мәкальдә *гыйшык* уңай хис буларак чагылыш таба һәм *дәрья* белән чагыштырыла. Татар халкы аңында чиксезлек дәрья булып күзаллана. Мәсәлән, татар халык әкиятләрендә еш кына Дию – Каф тавы артындагы дәрья төбендә көн күрүче зат, ә Каф тавы исә – чиклелек белән чиксезлекне аерып тора торган дивар: *Гыйшык – дәрья, йөзә белмәгән батадыр анда*.

Татар халык мәкальләрендә *мәхәббәт* бөтен кешелек дөньясын үзенә буйсындыра, тез чүктерә, кешене үзгәртә ала торган көч буларак күзаллана. Татарларда ир-ат – аз, ләкин үткен сүзле, гаиләне туйдырып һәм туендырып торучы, көчле кеше, ләкин гашыйк булган, мәхәббәт хисен татыган ир-ат – халыкның әлеге күзаллавыннан читләшә: *Гыйшык тотканда ир авызыннан сүз өзелмәс; дәрт* мәхәббәткә көч өсти торган компонент: *Мәхәббәт белән дәрт бердәй булса, йөрәк белән җан корбан булыр; мәхәббәт* көчен дөрес аңламаган кешенең тормышы аяныч тәмамланырга мөмкин: *Мәхәббәт акыллыны ашкындыра, акылсызны пошындыра.*

Мәхәббәт көче кешегә чит-ят предмет яки объектны кочтырырга да мөмкин: *Мәхәббәт тәпәнне дә кочаклата. Мәхәббәт* беркемне дә аямый торган көч: *Мәхәббәтнең күзе сукыр.*

Мәкаль һәм әйтемнәрдә *мәхәббәт* читтән күзәтеп тора торган зат буларак та күзаллана: *Ир белән хатын сугышканда, мәхәббәт бер почмакта тешләрен шыгыртатып торыр, ди*.

Объектив-субъектив характерга ия бәяләүнең рациональ яктан туплый торган (мөмкин булганча ышандырырлык итеп) һәм эмоциональ компоненты (бәяләнә торган объектка карата булган хис-тойгылар) була. Алар паремияләрдә гәүдәләнеш таба. Бәянең объективлыгы объектның үзенчәлекләрен чагылдыра торган күрсәткеч һәм тел коллективы әгъзаларының бәяләнә торган объектка булган ихтыяҗы белән, субъектив ягы исә аерым бер кешенең максат-ниятләре белән бәйләнгән [Җамалетдинов, 2006: 132].

Мәсәлән, мәкаль һәм әйтемнәрдә бәяләрнең түбәндәге төрләре күзәтелә:

1) әхлакый бәя, ул иң элек традицион халык әхлагы белән бәйле: *Мәхәббәт – өйнең яме; Мәхәббәтең читтә булса да, күңелең ак булсын;Алган ире яратса, кара хатын ак булыр;*

2) нәфасәти бәя, күренешләрнең тышкы якларын этник стереотиплардан, матурлык турындагы гадәти күзаллаулардан чыгып бәяләү белән бәйләнгән: *Мәхәббәт һәркемнең йөрәген матурлар; Йөзе матурны эзләмә, мәхәббәте көчлене эзлә;*

3) объектның үз вазифасына туры килүен истә тотып куелган функциональ бәя: *Матурлык кызга кирәк, мәхәббәт гаиләгә кирәк; Өйләнү – мәхәббәт белән бурыч; бу икәүсез булмас тормыш.*

Әмма традицион халык акылы еш кына бәяләрнең төрләрен аерып тормый, шуңа күрә паремияләрдә без еш кына бәяләр синкретизмына тап булабыз, аларның бүленмәс яки комплекслы характерда булуын күрәбез: *Мәхәббәт акчага сатылмас, күңел акчага табылмас; Мәхәббәт матурлык китерә, ачу йәмне үтерә;* мәхәббәт акча, ачу белән капма-каршы куела, ягъни аларда нәфасәти бәяләү формалары әхлакый бәяләү өчен кулланыла.

Шулай итеп, татар халык мәкальләре милләт аңында *мәхәббәт* хисе турында сакланган күзаллауларны ачарга ярдәм итә. Бу лексема эчтәлегендә татарлар тарафыннан дөньяны, тормышны аңлауның үзенчәлекле төрләре, кешенең шәхси тәҗрибәләре гомумилегә ята.

Димәк, татар паремиялогиясен лингвомәдәни яктан тикшерү – татар һәм, киңрәк планда алганда, төрки самими дөнья күренешен тасвирлауның зарури баскычы, чөнки мәкальләрдә халык аңының төп стереотиплары, милли мәдәнияткә хас булган әдәп-әхлак кагыйдәләре һәм идеаллары чагылыш таба. Актуаль лингвистик тикшеренүләрнең когнитив юнәлешле булуы телнең паремиологик фондын халык менталитеты һәм аның үзенчәлекләре турындагы мәгълүмат чыганагы буларак тикшерүгә этәргеч ясый.

Человек всегда жил во взаимосвязи с живой и неживой природой. Некоторые ее объекты он обожествлял, повиновался им, просил у них помощи, других представлял как злых духов и боялся их.

Такие формы мышления основывались на многочисленных традициях и верованиях народа. Со временем традиции менялись, некоторые забывались, а очень яркие и содержательные по смыслу сохранялись в виде разнообразных фольклорных жанров. В качестве объекта исследования нами были выбраны паремии и тексты народных песен, в других жанрах народного фольклора концепт “*Мәхәббәт” (Любовь)* не выражен.

Текстам паремий присуща ценностная характеристика, которая может рассматриваться только в лингвокультурологии.

Будучи культурным концептом, “*Мәхәббәт” (Любовь)* обладает ценностными характеристиками, которые можно установить, обратившись к анализу паремиологического фонда, являющегося одним из предметов изучения лингвокультурологии. Для национального сознания татарского народа, который относится к числу дисперсно проживающих народов, концепт “*Мәхәббәт” (Любовь)* имеет очень большое значение. Данный концепт часто связывается с образом родины, родной страны, с ностальгией по ней. Об этом свидетельствуют и татарские пословицы. Образ родины в них отражен эксплицитно: *Ватанны сөю – үзеңне сөю; Ватаннан аерылу сөйгәннән аерылудан яманрак.* Кроме того, любовь к родине, родной стране, природе противопоставляется могиле. *Туган илгә булган мәхәббәт салкын кабердә дә суынмас*.

Любовь к матери в пословицах представлена в сопоставлении с любовью ребенка: *Ана мәхәббәте балада, бала мәхәббәте далада*. Среди всех значений доминирует любовь межличностная – любовь между мужчиной и женщиной. В татарских пословицах любви (мәхәббәт) присущи долговечность, длительность отношений, а влюбленности (гашыйклык) – мимолетность: *Гыйшык уты кабына да сүнә, мәхәббәт гомер буе җылыта.*В основе долговечности любви лежит сама же любовь:

*Мәхәббәт мәхәббәт белән яши*. Несмотря на это, влюбленность, как и любовь, имеет и положительное значение в контексте паремиологий. Она сравнивается с океаном, бесконечным водным пространством и, таким образом, наделяется долговечностью, длительностью существования: *Гыйшык – дәрья, йөзә белмәгән батадыр анда*.

В текстах паремий любовь представляется в женском облике: *Мәхәббәт нәфрәткә яулык болгый (Любовь ненависти машет платком).*

Такие характерные для татарских женщин качества, как терпение и верность также отражены в пословицах о любви: *Хатыннар мәхәббәтне күңелләрендә кырык ел сакларлар, сөймәгәнлекләрен бер сәгатьтә ачып салырлар (Женщины могут хранить любовь в душе и сорок лет, а отвращение выскажут за час)*.

Любовь в пословицах представляется как сила, подчиняющая себе, меняющая исторически сложившиеся устои: *Мәхәббәт белән дәрт бердәй булса, йөрәк белән җан корбан булыр (Если и любовь, и страсть будут за одно, то душа и сердце перейдут в иной мир); Мәхәббәт акыллыны ашкындыра, акылсызны пошындыра (Любовь для умного – наслаждение, а для глупого – мучение); Гыйшык тотканда ир авызыннан сүз өзелмәс (У влюбленного мужчины из уст так и льются слова); Мәхәббәт тәпәнне дә кочаклата (Любовь заставит обнять и бочку); Мәхәббәтнең күзе сукыр (У любви глаза слепы)*.

Любовь для татарского народа – это мудрое существо, осуждающее неблаговидные поступки: *Ир белән хатын сугышканда, мәхәббәт бер почмакта тешләрен шыгырдатып торыр, ди (Когда муж и жена дерутся, то любовь наблюдает из-за угла, скрипя зубами)*.